**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.01.2026 **Чирмешән авылы** **№ 3**

**Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибен 1нче кушымта нигезендә ракларга.

2. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнар (контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләре), махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә башкаручы гражданнар (ирекләләр), шул исәптән Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән, Донецк халык республикасы, Луганск халык республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба – гаиләләр) каты ягулык белән тәэмин итү рәвешендә – (алга таба – каты ягулык), аны да китерүне дә кертеп, өстәмә ярдәм чарасы билгеләргә.

3. Күрсәтелгән ярдәм чарасы карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларга

ике елга бер тапкыр күрсәтелә.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эше буенча ярдәмчесе А.Я. Сәйфетдинованы махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) каты ягулык белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтеп җиткерүне дә кертеп, өстәмә ярдәм чарасы күрсәтү тәртибе нигезендә өстәмә ярдәм чарасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
16.01.2026, № 3

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтеп җиткерүне дә кертеп, өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык (яфрак токымлы агачларның киселгән рәвештәге технологик утыны) – (алга таба – каты ягулык) белән тәэмин итү рәвешендә өстәмә ярдәм күрсәтү шартларын һәм күләмнәрен билгели, аны илтеп җиткерүне дә кертеп.

2. Каты ягулык (яфрак токымлы агачларның технологик утыны) бары тик мич белән генә, шул исәптән утын белән эшли торган автоном җылыту системасы (алга таба - мич белән җылыту) белән җылытыла торган бер бүлмәгә 6 (алты) куб.метр күләмендә бирелә.

3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык белән тәэмин итү һәм илтеп җиткерү чараларын оештыру белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эше буенча ярдәмчесе (алга таба – белгеч) шөгыльләнә.

4. Каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм илтеп җиткерүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасы күрсәтелә торган махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәге затлар аңлашыла (алга таба-гаилә әгъзасы):

- махсус хәрби операциядә катнашучының яшәү яисә булу урыны буенча теркәлгән хатыны (ире) һәм (яисә) аның балигъ булмаган балалары;

- махсус хәрби операциядә катнашучының әтисе яки әнисе (әти-әнисе).

5. Әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән гаилә әгъзаларына каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм илтеп җиткерүгә бәйле өстәмә ярдәм күрсәтү мөрәҗәгать итү характерында була.

6. Каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм илтеп җиткерүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасын алу максатында әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән гаилә әгъзасы белгечкә әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтадагы форма буенча түбәндәге документлар белән гариза бирә:

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ;

- махсус хәрби операциядә катнашучы статусын раслый торган документ;

- гаилә әгъзасының һәм махсус хәрби операциядә катнашучының туганлыгын (үзлеген) раслый торган документ (туу (уллыкка алу) турында таныклык, никах турында таныклык, туганлыкны (үзлеген) раслый торган башка документ);

- мич җылытуы булу турында мәгълүматны үз эченә алган документ;

- махсус хәрби операциядә катнашучының вафат булуы турында таныклык-махсус хәрби операциядә катнашучының һәлак булган (вафат булган) катнашучысының гаилә әгъзалары булган затлар өчен.

Гаризада кабул ителгән карар турында хәбәр итү ысулы күрсәтелә (шул исәптән почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы).

Документларның күчермәләрен гаилә әгъзасы һәр кәгазьгә шәхси имза кую юлы белән таныклый.

Документларның күчермәләрен тапшырганда, документларның төп нөсхәләре карап чыгу өчен күрсәтелә.

Гаилә әгъзасы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

7. Кергән документлар белгеч тарафыннан аларны тапшырган көнне үк теркәлә.

8. Гариза Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан теркәлгән көннән алып 10 (ун) эш көненнән артмаган вакытта карала.

9. Гаризаны карау йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

каты ягулыкны (киселгән рәвештә яфрак токымлы агачларның технологик утыны) тәэмин итү һәм илтеп җиткерү турында;

каты ягулыкны (киселгән рәвештә яфрак токымлы агачларның технологик утыны) тәэмин итүдән һәм илтеп җиткерүдән баш тарту турында.

Күрсәтелгән карар язма хәбәрнамә рәвешендә гаилә әгъзасына гаризада күрсәтелгән ысул белән әлеге Тәртипнең 8 бүлегендә билгеләнгән гаризаны карау срогыннан да соңга калмыйча җибәрелә.

10. Каты ягулыкны тәэмин итүдән һәм илтеп җиткерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигезләр булып тора:

әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән затлар категориясенең туры килмәве;

тапшырылган документларда дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүмат ачыкланды;

мич җылытуы булмау;

чистартулар яисә өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм аларда килештерелмәгән башка төзәтмәләр, документның текстын укырга һәм аның эчтәлеген бер мәгънәдә аңлатырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар булган документларны тапшыру;

гаилә әгъзасы тарафыннан гаризаны кире алу;

әлеге Тәртипнең 6 бүлегендә күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын тапшыру.

11. Баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәндә каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм илтеп җиткерүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасын күрсәтү өчен документлар әлеге Тәртип нигезендә белгечкә яңадан тапшырылырга мөмкин.

12. Каты ягулыкны гаилә әгъзасы күрсәткән адрес буенча илтеп җиткерү каты ягулыкны тәэмин итү һәм илтеп җиткерү турында карар кабул ителгән вакыттан алып 90 (туксан) календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтеп җиткерүне дә кертеп, өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибенә 1нче кушымта

_______________________________________

(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.Ат.ис.)

"___" ________________ туу датасы

паспорт серия______ N ______________,

бирелгән ______________________________

_________________________________,

(кайсы орган тарафыннан, бирү датасы)

түбәндәге адрес буенча теркәлгән:

____________________________________

тел. _______________________________

электрон почта адресы:

____________________________________

## ГАРИЗА

Гражданин___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________________________,
(махсус хәрби операциядә катнашучының Ф.И.Ат.ис., туу датасын, теркәлү адресын, категориясен күрсәтегез)

______________ булып торам.
(туганлык дәрәҗәсен күрсәтергә)

Түбәндәге адрес буенча урнашкан _______ җылыту өчен 5 куб метр күләмендә каты ягулык (озынлыгы 1,5 метрдан 3 метрга кадәр озынлыкта булган яфрак токымлы агачлардан технологик утын) белән тәэмин итүне һәм китерүне оештыруны сорыйм:___________________________________________________________________________
______.

Әлеге гариза белән үзем, гаиләм һәм мөлкәтем турында дөрес булмаган мәгълүматлар бирү өчен тулысынча җаваплы булуымны раслыйм.

Әлеге гариза белән раслыйм, миңа элек махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзаларына каты ягулык белән тәэмин итү һәм илтү белән бәйле өстәмә ярдәм күрсәтелмәгән иде.

Кабул ителгән карар турында миңа шәхсән, почта, электрон почта аша хәбәр итүегезне сорыйм. ____________________________________________________________.
(электрон почта адресын күрсәтергә / кирәклесен ассызыкларга)

Кушымта:

Әлеге гаризада булган шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән (чикләүсез) мәгълүмат алмашу гамәлләрен башкару өчен җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), файдалану, өченче затларга тапшыруга, шәхси белешмәләрне шәхессезләндерүгә, блоклауга, шулай ук Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган теләсә нинди башка гамәлләрне башкаруга ризалык бирәм.

Әлеге гаризадагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге ризалыкны кире алу турында гариза бирелгән көнгә кадәр гамәлдә була.

"___" ___________20 ___ ел ____________________ ______________

(Ф.И.Ат.ис.) (имза)